**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлегенең Ямкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча**

17 декабрь 2021 е. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге составына керүче Ямкино авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Алексеевск шәһәр җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, студентлар, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнар керми, һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:

- торак пункт урамнарын төзекләндерү һәм карап тоту.

2. Әлеге карарны Войкино авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Войкино авыл җирлеге башлыгы** **Н.П. Шәбетдинова**